СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)3-92-40, факс (84366)3-92-40. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru


**Апаз җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

25 февраль 2022 ел № 64

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Советының 2021 елның 03 декабрендәге 57 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында.**

«Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 06 декабрендәге 397-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында " 03.12.20021 ел, № 57 карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 190 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) хайваннар авыруларын кисәтүне һәм хайваннардан алынган продуктларның ветеринария-санитария ягыннан куркынычсызлыгын тәэмин итә торган хуҗалык һәм ветеринария чараларын башкарырга, әйләнә-тирә мохитне хайваннардан алынган калдыклар белән пычратуга юл куймаска, шулай ук ел саен яңадан теркәү чорында мәҗбүри дәвалау-профилактик чаралар үткәрергә;».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов